**СОВЕТ НИКОЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422627 с. Никольское,
ул. Центральная, д.35
тел: 4-31-44

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ НИКОЛЬСКИЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422627 Никольский авылы,
Әзәк урамы, 35 нчы йорт,
тел: 4-31-44

---

**2020 елның 17 марты** **4 номер**

# КАРАР

## Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Никольский авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» 2018 елның 12 ноябрендәге 24 номерлы Никольский авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы законга, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы законга, «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы, «Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы законга, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 декабрендәге 477-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль законның 15 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2017 елның 29 декабрендәге 477-ФЗ номерлы Федераль законга ярашлы рәвештә, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2017 елның 13 апрелендәге 711/пр номерлы «Җирлекләр, шәһәр округлары, шәһәр эчендәге районнар территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләрен әзерләү өчен методик тәкъдимнәр» боерыгы нигезендә, Россия Федерациясе Дәүләт төзелешенең 1999елның 15 декабрендәге 153 номерлы боерыгы белән расланган Россия Федерациясе шәһәрләрендә яшел үсентеләр барлыкка китерү, аларны саклау һәм тоту кагыйдәләренә таянып, «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Никольский авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына таянып, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Никольский авыл җирлеге территориясендә санитар һәм экологик торыш, чисталык һәм тәртип саклау өчен предприятиеләрнең, оешмаларның, учреждениеләрнең, вазыйфаи затларның һәм гражданнарның җаваплылыгын көчәйтү һәм арттыру максатларында Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Никольский авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Никольский авыл җирлеге Советының 2018 елның 12 ноябрендәге 24 номерлы«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Никольский авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында»гы карарына, кушымта нигезендә, үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Никольский авыл җирлегенең торак пунктлары территориясендә- ТР, Лаеш районы, Никольский авылы,Центральная ур.,35 йорт; Центральная ур.,43 йорт адреслары буенча махсус җиһазландырылган стендларда бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Башлык- ТР Лаеш муниципаль районы**
**Никольский авыл җирлеге Советы рәисе** **Э.Х.Алеев**

2020 елның 17 мартындагы
4номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Никольский авыл җирлеге советы карарына кушымта

**«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Никольский авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» 2018 елның 12 ноябрендәге 24 номерлы Никольский авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр**

1. 94 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«94. Гомуми файдаланудагы барлык парковкаларда, шул исәптән социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектлары (торак, иҗтимагый һәм җитештерү биналары, төзелешләр һәм корылмалары, физик культура-спорт оешмалары урнашкан, мәдәният оешмалары һәм башка оешмалар), ял итү урыннары янында, бушлай парковка өчен, I, II төркем инвалидлар белән идарә ителә торган транспорт чараларына һәм мондый инвалидларны һәм (яисә) инвалид балаларны ташучы транспорт чараларына урыннарның кимендә 10 проценты ( кимендә бер урын) бүлеп бирелә. III төркем инвалидлар арасыннан булган гражданнарга әлеге пункт нормалары Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә карала.

Күрсәтелгән транспорт чараларында "Инвалид"дигән  тану билгесе билгеләнергә һәм әлеге транспорт чаралары турындагы мәгълүмат инвалидларның федераль реестрына кертелергә тиеш.»